**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 20 маендагы 1727 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 8 августындагы 4720 номерлы «Казан шәһәре муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

Программа-максатчан идарә итү системасын камилләштерү һәм программа-максатчан принцип нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетын формалаштыруга күчү юлы белән бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыру, стратегик һәм бюджет планлаштыруның тыгызрак бәйләнешен тәэмин итү, Казан шәһәре Башкарма комитеты органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатыннан **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 8 августындагы 4720 номерлы «Казан шәһәре муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында»гы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенә, 2 номерлы кушымтаны әлеге карарның кушымтасы нигезендәге редакциядә биреп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның  20 маендагы
1727 номерлы карарына
кушымта
(Форма)

## Муниципаль программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чараларын финанслау

| № | Төп чаралар исемнәре | Башкару-чылар | Төп чараларны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | Чыганагын күрсәтеп, финанслау | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | база елы | 1 ел | 2 ел | n-нчы ел | 1 ел | 2 ел | n-нчы ел |
| **Максатның атамасы** | | | | | | | | | | | |
| **Бурычның атамасы** | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | |